Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге составына керүче Белоус авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

«14» апреле 2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә гражданнар җыены

КАРАР БИРДЕ:

1. Үзгәрешләр кертергә:

1) түбәндәге редакциядә бәян итеп, гражданнар җыенына чыгарылган һәм кабул ителгән «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге составына керүче Белоус авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 16 ноябрендәге 9 номерлы гражданнар җыены карарына:

-торак пункт территориясен төзекләндерү (кечкенә архитектура формаларын (балалар уен, спорт җиһазлары, кибетләр, вазондар, коймалар, хуҗалык блогы балалар мәйданчыгын каплау өчен ком сатып алу);

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (юлны ремонтлау, вак таш, асфальт ватыклары сатып алу, махсус техника хезмәтләре);

2) 1 пунктның икенче-өченче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итеп, 2023 елның 16 ноябрендәге 10 номерлы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Белоус авылында гражданнар җыены карарына:

-торак пункт территориясен төзекләндерү (кечкенә архитектура формаларын (балалар уен, спорт җиһазлары, кибетләр, вазондар, коймалар, хуҗалык блогы балалар мәйданчыгын каплау өчен ком сатып алу);

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (юлны ремонтлау, вак таш, асфальт ватыклары сатып алу, махсус техника хезмәтләре).

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә махсус мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarsatan.ru), Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүматы порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы
Кече Шилнә авыл җирлеге советы рәисе,
Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы
Кече Шилнә авыл җирлеге Башлыгы А.Г. Даутов